**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2022 елның «28» февраленнән № 19-144

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәге карарларны үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштырганда муниципаль заказчыларның үзара хезмәттәшлеге тәртибен раслау турында» 2010 елның 16 декабрендәге 3-24 номерлы карары;

- Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларны үтәмәгән һәм мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу таләпләрен үтәмәгән өчен түләтүләрне куллану турында» 2012 елның 22 маендагы 12-104 номерлы карары;

- Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Яңа Чишмә муниципаль районының Контроль-хисап палатасы турындагы нигезләмә турында» 2006 елның 20 июлендәге 9-67 номерлы карары (2009 елның 16 гыйнварындагы 30-204 номерлы, 2009 елның 27 маендагы 34-231 номерлы карарларындагы үзгәрешләр белән);

- «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә җирләрдән файдалануга муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру буенча административ регламентны раслау турында»Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2011 елның 28 гыйнварындагы 4-32 номерлы карары;

- Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә җирләрне файдалануга муниципаль җир контроле турындагы нигезләмә турында» 2008 елның 16 гыйнварындагы 22-135 номерлы карары;

- Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Медицина хезмәтләренә бәяләрнең прейскурантын раслау турында» 2010 елның 16 июнендәге 46-285 номерлы карары;

- Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Яңа Чишмә муниципаль районында «Россия гражданнарына - һәркем алырлык һәм уңайлы торак»

милли проектын гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча комплекслы программа турында» 2006 елның 23 ноябрендәге 10-72 номерлы карары.

2.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы

В. М. Козлов